Фирая Зыятдинова




Казан ● Татарстан китап нәшрияты ● 2003

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
З 82

*АЛЛА АЙСИНА* рәсемнәре

МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

**Зыятдинова Фирая**

З 82 Бака туе: Шигырьләр.— Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. — 80 б.

Китапта шагыйрә Фирая Зыятдинованың мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен шигырьләре тупланды.

ISBN 5–298–01330–9 © Татарстан китап нәшрияты, 2003

## Татарча белмәүче кәҗәләр

Шундый безнең Алиябез:
Үлеп әкият ярата.
Сөйли аны әнисе дә,
Сөйли аны Марат та...
Әкият иле Алиянең
Туган иле диярсең!..
Бердәнбер кызың сорагач,
Әлләниләр сөйләрсең.
«Козлятушки, дитятушки,
Ваша мать пришла —
Вам молочка принесла...»
Кәҗә шулай җырлый, диеп
Сөйләп китә әнисе.
Урысчалап такмаклауга
Алия соң ни дисен?!
Тыңлап-тыңлап тора да ул
(Тыңлый белә ул үзе!),

Әнисе сөйләп бетергәч,
Әйтеп куя үз сүзен:
— Бу кәҗәләр бер генә дә
Татарча белмиләрме?
Татарчаны белмәгәнгә,
Урысча сөйлиләрме?



## *Кызып китте Алия*

Алиягә дәү әнисе
«Бәбекәем» дип дәшә.
Әтисе дә, әнисе дә
Үзебезчә сөйләшә.

Урысчасы бераз аксый,—
Нихәл итсен Алия?
Бүтән телләр качмас әле,
Ана теле баш өйдә.

Алиянең теле дә бит
«Әннә» диеп ачылды.
Ана телен яратмый соң
Йә, әйтегез, кайсыгыз?

Бүтән телләр дә өйрәнер,
Үсә төшсен Алия.
Ә хәзергә ана телен
Судай эчсен Алия.

Бакчаны бик ярата ул,
Ярата апасын да.
Кайчакларны килми хәтта
Бакчадан кайтасы да.

Тик шулай да беркөн менә
Кызып китте Алия,
Үзен-үзе бүлә-бүлә
Тезеп китте Алия:

— Татарча гына сөйләшә,
Гел татарча орыша:
Гөлназ апа бер генә дә
Белми, ахры, урысча...

## *Юату*

Марат инде җиде яшьтә,
Алиягә өч кенә.
Үзе кечкенә булса да,
Эче тулы төш кенә.
Дөнья күргән әбиләр күк —
Алдап булмый һич менә.
Әниләре әйткән иде
Әле бүген кич кенә:

— Нишләтергә инде сезне,
Тыңламыйсыз һич менә.
Иртән чыгып китәрмен дә
Кайтмам, ахры, кич белән.
Миңа мондый тыңлаусызлар,
Елаклар кирәкми лә!
Әни сүзен тыңлый торган
Балалар кирәк миңа.

Ничек инде ул әнисез,
Ничек инде ул алай? —

Маратның ике күзеннән
Мөлдер-мөлдер яшь тама.
Кем иркәләп уятыр соң,
Әни булмагач өйдә?
Кем пешереп ашатыр соң
Тәмле-тәмле әйберләр?

Марат шулай елап тора,
Алия уйламый да.
(Ул бит инде дәү үскән кыз, —
Дәү кызлар еламыйлар!)
Әле абыйсын юата:
— Кайта, кайта әнием!
Бездән башка торалмый ул,
Курыкма син, абыем!

# *Бака туе*

Су буеннан, кош тоткандай,
Кайтып керде Алия:
— Бу бака балаларының
Юк икән әтиләре дә,
Юк икән әниләре дә.
Мин аларны кызгандым,
Җыеп чиләккә салдым.
Әйдә, бездә торсыннар,
Безнең бака булсыннар, —
Дип, Алия идәнгә
Куйды яшел чиләген.



Шуннан әллә нишләп киттем:
Ярылдымы йөрәгем?
Көләргәме, еларгамы?
Нишлим икән? Уф, үләм! —
Бөтен идән тулды шунда
Бармак башы хәтле генә
Бака малае белән.
Шуннан ни булды, дисез?
Әйтмәсәм, һич белмисез!
Кыш буена рәхәтләнеп
Бака хорын тыңладык.
Кайчакларны үзебез дә
Хорга кушылып җырладык:
«Бака-ка-ка, бака-ка!
Без бакалар яратабыз,
Алар безне ярата.
Бака-ка-ка, бака-ка!
Бака-ка-ка, бака-ка!»
Кыш буена өебездә
Без бик кызык яшәдек.
Шундый кызык яшәдек —
«Бака туе» ясадык...

## *Кемгә кызым диярсең?*

— Җимешем син, матурым син,
Алтын бөртегем минем.
Ашап-ашап, ашап-ашап,
Ашап бетерер идем...

Ратуга түзалмыйча,
Әнисе шулай сөя.
Кара күзләрен тутырып
Карап тора Алия:

— Мине ашасаң, әнием,
Кемне шулай сөярсең?
Кемне шулай яратырсың,
Кемгә «кызым» диярсең?

## *Әзер җавап*

— Әй кызым, кызым минем,
Кызым, йолдызым минем.
Уятмасаң, йоклар идең,
Ахры, көнозын,— димен. —

Әллә кайчан сикереп торды,
Әнә кара Маратны!
Күп йоклаган кызларны бит
Малайлар да яратмый.

Андый кызларны әтиләр
Бакчадан да алмыйлар.
Алиянең җавап әзер:
— Ә мин анда бармыйм да!

## *Алия «кәҗәләнә»*

— Мин бакчага бармыйм бүген,
Арыдым, туйдым инде.
Әнием, дим, бүген генә
Өйдә утырыйк инде?!

— Алай булгач, утыр үзең,
Барма инде бармасаң...
— Үзем генә куркам шул мин,
Барыйк инде, алайса...

## *Бакчага барасы бар*

— Әйдә, кызым, тор инде, тор,
Соңга калдык, тиз киен!

— Әйттем ич инде, әнием,
Мин бик торыр идем дә бит,
Күзем ачылмый, дидем...

## Тапкыр кыз

— Хәзер, кызым, син мине
Яратасың, сөясең.
Әнием, дип, алтыным, дип,
Битләремнән үбәсең.

Картайгачтын, аргачтын,
Күзлек киеп алгачтын,
Бу маңгайны, битләрне
Җыерчыклар саргачтын,

Чәч агаргач, бил бөкрәйгәч,
Ямьсезләнермен инде,
Җимеш кебек татлы булмам,
Тәмсезләнермен инде...

Шулчак кем диеп дәшәрсең?
Мин соң ничек яшәрмен?
— Бер дә борчылма, әнием,
«Әбием» дип дәшәрмен.

## *Телефон*

Әнисе кайтканны көтеп
Алия тәмам арды.
Тәрәзәдән карый-карый
Инде күзләре талды.

Кинәт — чылтыр-р! Марат барып
Телефонга ябышты.
Ур-ра! Ур-ра! — Трубкада
Әниләре тавышы.

— Менә әни белән сөйләш, —
Диде Марат абыйсы.
Шундук таныды Алия
Әнисенең тавышын.

Тавышы бар, үзе кайда? —
Аптырады Алия.
Кычкырып елап әнисен
Таптыра бит Алия!

Марат тәмам хәлдән тайды
Алияне юатып.

Аптырагач, сүтеп салды
Телефон аппаратын.

Шөрепләр китте тәгәрәп,
Әнә ята капкачы.
Менә ята трубкасы,
Менә монда тартмасы...

Ватык телефонны күргәч,
Тынып калды Алия.
Әни дә юк, телефон да —
Тынычланды Алия.

## Дөрес аңлаган...

Ашыккан ашка пешкән, ди...
Әбинең алтын сүзләрен
Әле генә төшендем:
Әни бүлеп биргән ашны
Кабаланып капкан идем,
Авызымны пешердем!..

## Ботка түгел...

— Нигә ашамыйсың, улым,
Әллә ботка артык кайнар?
— Юк, әнием, ботка түгел,
Никтер менә кашык кайнар...

## *Карадым да карадым...*

Бүрене дә карадым,
Куянны да карадым,
Карадым да карадым.
Әле тагын карар идем...
Ярый, җитәр, ятыйм инде, —
Телевизор аргандыр...

## *Үсәсем бар...*

Эшчән кеше тиз үсә, ди, —
Белми әйтмәс әнием.
Үсәсем бар: мин бит әле
Төпчек улы әнинең.

Кушканны да көтми эшлим —
Бик үсәсем килә ич!
Көн дә үсәм — әниемә
Зуп-зур егет кирәк ич!

## *Алтын сукмак*

Су өстендә алтын сукмак:
Кояшта җем-җем итә.
Белсәң иде, ул якты юл
Кайларга кадәр илтә?

Икенче ярга кадәрме,
Диңгезгә койганчымы?
Күзләремне ала алмый
Карадым туйганчы бер.

Матурлыкта һич тиңе юк —
Кояш бит салган аны.
Шул вакыт күкне кап-кара
Болытлар каплап алды.

Тагын бер карадым суга —
Алтын сукмак югалган.
Күңелемдә ул кузгаткан
Дулкыннар гына калган.

## *Бик ярата мине эш...*

Әллә үзен яратканга —
Бик ярата мине эш.
Мин барын да эшләргә,
Мин өлгерергә тиеш!

Кызлар эше диеп тормыйм —
Савыт-саба да юам.
Әнием эштән кайтуга,
Табын әзерләп куям...

Тавык чүпләсә дә бетми
Өй эше, ди әнием.
Булышмыйча нихәл итим —
Кызы юк бит әнинең!

## *Җиңелмени?..*

— Сөтне каян алалар,
Беләсезме, балалар?

Айнур әйтте: — Мин беләм —
Башта каймак алалар,
Аннары су салалар,
Аннары болгаталар —
Килә чыга тәмле сөт...
Моны ишеткәч, һәммәсе
Рәхәтләнеп көлеште.

Ә ник әле көләргә?

Болыннарда йөрмәгәч,
Сөтбикәне күрмәгәч,
Каян белсен ди Айнур
Сөтне каян алганны?!
Җиңелмени аеруы
Булган хәлдән ялганны...

## *Кошлар туе*

Җимлек ясады Айнур,
Шундый матур җимлеге!
Кызылтүшләр, песнәкләр
Белсен әле кемлеген!

Коштай очып, канатланып
Чыгып китте урамга —
Үзе ясаган җимлекне
Талга элеп куярга.

Иртәгесен ниләр күрсен! —
Вәт тамаша, вәт уен! —
Әллә сабан туемы бу?
Юк ла, бу кошлар туе:

Бөтен урман кызылтүше,
Бөтен урман песнәге
Бар да шунда җыелган,
Авыз итик әле, диеп,
Айнур дусның сыеннан...

Айнурның бит дуслары да
Үзе кебек уңганнар:
Иртәгесен ботак саен
Җимлек элеп куйганнар!



Бу ни гаҗәп хәл бу тагын?
Ни тамаша, ни уен?
Әллә сабан туемы бу?
Юк ла, бу кошлар туе!

Бөтен урман кызылтүше,
Бөтен урман песнәге
Бар да шунда җыелган,
Авыз итик әле, диеп,
Дусларыбыз сыеннан.

Чыпчыклар да очып килгән,
Күгәрченнәр җыелган...
Кем соң инде баш тартсын ди
Шундый кунак сыеннан?!

## Айнур үпкәләде

Ап-ак кына, йомшак кына
Кар явып үткән кичтән.
Мондый матур, йомшак карны
Ул көтә инде күптән.

Тәгәрәтеп җепшек карны,
Ясап куйды Кар бабай.
Менә, малай, бабай инде —
Бар бабайларга бабай!

Иртәгесен Айнур, торып,
Тәрәзәдән караса,



Кар бабайдан җилләр искән —
Эреп беткән ләбаса!

Айнур аңа үпкәләде,
Үзен ташлап киткәнгә:
«Чын кыш түгел икән лә бу —
Алдакчы кыш икән лә!..»



## *Кызык икән...*

Кыш бабай ул саран түгел —
Кардан таулар өеп куйган.
Юл ярулар җиңелмени
Кар көртләре арасыннан?!

Зарлана дип уйламагыз, —
Көне нинди матур бүген!
Кош тоткандай куанамын,
Тигез ике эзне күреп.

Үзем салган эзләр бит ул,
Иң беренче салган эзләр!
Мондый көнне ничек түзсен?! —
Дусларым да чыгар тиздән.

Акбүз аттай бураннарның
Ялларына ябышырбыз;
Бергә-бергә шаян-елдам
Җилләр белән ярышырбыз...

Очып кына үтеп киттем
Алда торган текә тауны...
Кызык икән, рәхәт икән
Юлны үзең салулары!

## *Уйный-уйный үсәм мин*

Курыкмыйм мин бураннан —
Кайтып кермим урамнан.
Өйдә нәрсә бар анда?
Бөтен кызык урамда —
Бөтен кызык буранда.

Авылыбыз да ап-ак,
Урамыбыз да ап-ак.
Шәһәрнеке кебек түгел —
Бураныбыз да ап-ак.

Яратам мин буранны,
Ап-ак карлы урамны.
Ап-ак көртләргә чумам,
Ак малай булып чыгам.

Ак кар булып төреләм,
Җилләр булып исәм мин.
Бураннар белән ярышып,
Уйный-уйный үсәм мин.



## *Мин андый малай түгел!*

Өйдә әни: «Бу салкында
Йөрмә,— ди,— туңарсың»,— ди.
Ә урамда җил өркетә:
«Кереп кит, еларсың»,— ди.
    Биек таулар: «Без биек,— ди,—
    Менмә,— ди,— егылырсың.
    Барыбер,— ди,— ярты юлдан
    Кирегә борылырсың...»
Һәрберсенең үз туксаны,
Һәрберсенең үз сүзе.
Соң мин дә бит егет кеше,
Мин үзем дә үзсүзле!
    Соң бит алар дөрес әйтми,
    Соң бит ул алай түгел!
    Егылганга елап тормам —
    Мин андый малай түгел!
Суыктан да куркып торсам,
Адым саен егылсам,
Биек тауга меналмасам,
Ярты юлдан борылсам,
    Мин нинди егет булыйм? —
    Мин бит әтием улы!

## *Дәүдер җилнең авызы*

Әти белән урманга
Киттек чаңгы шуарга.

Урманга әле ерак,
Барабыз кырлар буйлап.

Барабыз җайлап кына,
Көртләрне сайлап кына.

— Кырлар бит такыр калган —
Карын җил ялап алган, —

Ди әти, үзе көлә
(Ул инде барын белә!), —

Дәүдер җилнең авызы —
Кара син ул явызны!

Шундый да юньсез булырга,
Шундый да комсыз булырга
Ярый димени инде?!

## *Акланды...*

— Әни, бүген «бишле» алдым!
Апа мине мактады
Бөтен класс алдында!

— Тагын нинди билге алдың?
— Тагын... тагын...
Әй, «икеле» алдым ла...

— Анысы ник инде, улым?

— Әни, син бик кайгырма
(Айнур бераз уйланды):
Минем «ике» нәни генә,
Менә моны-ың чаклы гына...
Рәмзинекен күрсәң иде,
Шундый симез —
Дәфтәренә сыймады!..

## *Килми калмас әле ул...*

Күрдем бүген бер песнәкнең
Тәрәзәне какканын,
Күрдем, эзләп аргач кына,
Бер бөртек җим тапканын.

Тәрәзәмне ачкан идем,
Кер, дип тә дәшкән идем,
Ут булды да юк булды —
Очты китте песнәгем!

Бигрәк инде! Шундый куркак
Булырга ярый микән?
Тагын килер микән песнәк?
Ә мине таныр микән?..

Песнәкләрне яратканны
Белми калмас әле ул,
Күмәч белән сыйланырга
Килми калмас әле ул!

## Кайт, песием!

Ачтым өйнең ишеген —
Чыкты качты песием.
Күр әле син бу мутны —
Җирән купшы койрыкны!..
Эзләдем, арып беттем,
Әллә кайларга җиттем.
Юк кына бит песием,
Инде хәзер нишлием?!
Баш ватам да баш ватам:
Кайларда булган хатам?
Әллә инде мут кынам,
Җирән-ут койрык кынам
Эшсезлектән туйганмы?
Йоклап гарык булганмы?
Оятына көч килеп,
Эшләп ашыйсы килеп,
Орышмасыннар, диеп,
Эш эзләп киткән мәллә
Күселе берәр өйгә?

Песи, песи, пескәем,
Яшел ялкын күзкәем,
Нишлим соң инде синсез?
Синсез шундый күңелсез!
Өйләрнең дә яме юк,
Ашларның да тәме юк.
Йөрмә инде мутланып,
Койрыгың сыртка салып.
Кайтып кер инде өйгә,
Болай йөрүләр нигә?
Эшне үзем табармын,
Сөеп кенә багармын
Яшел ялкын күзеңә,
Кайт, песием, кайт өйгә!

## Куян

Җыям, җыям, җыям да
Илтәм дустым Куянга.
Нәрсә илтә, дисезме?
Шуны да белмисезме?
Куян кишер ярата,
Кәбестәгә дә риза.
Куянның кызыл күзе
Чөгендергә дә кыза.
Күсе-тычканнар тотмый,
Куян ул песи түгел.
Кучтәнәчкә кишер-мишер
Көтә ул миннән бүген.
Гел уен да гел уен
Булмады быел уем.
Сулар сибеп үстердем
Кишер, кәбестә, суган...
Суганын алып тормам —
Суган яратмый Куян.

Менә шундый ул Куян —
Куян — ве-ге-та-ри-ан!



## *Тавык*

Коймада тишек табып,
Бакчага кергән тавык.
Кыт-кыт-кыт килгән була,
Кыланып йөргән була,
Түтәлләрдә казына,
Азган саен азына.
Карап-карап тордым да,
Юк мыекны «бордым» да,
«Тукта, дим, кызык итим
Бу юньсез җан иясен:
Икенчеләй түтәлләрне
Таптап-изеп йөрмәсен.
Хәзер мин аны тотам,
Койма аша ыргытам!»
Шуннан китте чабышу —
Әйтерсең лә ярыш бу!
Чабабыз пыр туздырып,
Бер-беребездән уздырып.
Ярты сәгатьләп чапкач,
Арып, әлсерәп беттек.
Түтәлне дә «эт иттек»,
Табылмый теге тишек.

Чыгалмагач тишектән,
(Ничекләр башы җиткән?!)
Тәмам алҗыган тавыгым
Уктай чыгып ычкынды
Ачык калган ишектән!..

## *Бал корты*

Беркөн болында йөрдем,
Бик күп чәчәкләр күрдем.
Ниләр генә юк монда —
Безнең яшел болында!
Кызыл чәчәк, ал чәчәк,
Ак чәчәк тә күк чәчәк —
Шундый-шундый күп чәчәк!
Берсеннән-берсе матур,
Берсеннән-берсе тату.
Урын да тар, димиләр,
Бер-берсенә тимиләр.
Кычкырып сөйләшмиләр,
Әрләшми, тиргәшмиләр.
Бер-берсен яраталар,
Бөтен болын өсләренә
Хуш исләр тараталар.

Һәрберсенә җайлап кына
Бал корты килеп куна.
Бал кортларының җырыннан
Тирә-юнь гөжләп тора...
Ой!
Нечкә билле бер бал корты
(Әллә чәчкә дип белде?)
Миңа да килеп кунды.
Ә мин, ул очып киткәнче,
Селкенергә дә куркып,
Кузгалмый басып тордым.

## *Чебен*

Килә дә куна битемә —
Тәмам туйдырды чебен.
Тотыйм гына дигән идем,
Чыгарды миңа телен.
Аннан көлгәндәй итте,
Очып йөргәндәй итте.
Туйганчы бер уртәде дә
Тәрәзәбездән урамга
Очып чыкты да китте.

## *Куян гозере*

— Бик авырта колакларым,
Тотма әле колагымнан!
Уф!
Ничек кенә котылырга
Бу малайның кулларыннан?!
Колагы озын дигәч тә,
Күзләре кылый дигәч тә,
Тырнагы үткен дигәч тә,
Шулай кыланырга ярыймы?
Әнә ул сусыл үләнне,
Кәбестә белән кишерне,
Баллы кызыл чөгендерне
Алдыма гына куялсаң,
Аннан күз алдымнан югалсаң,
Озын, матур колагыма тимәсәң,
«Әй, син, кылый күз!» — димәсәң,
Син китергән тәмле сыйны
Кетер-кетер кимерер идем,
«Җир йөзендә
Иң әйбәт малай
Бары ул!» — дияр идем.
Уф!
Тимә озын колагыма!



## *Кызылтүш*

Тал башында, күзен кысып,
Утыра бер кызылтүш.
Үзе ялт та йолт карана:
Безне күзәтә, имеш!

Нигә безне күзәтә ул,
Нигә башын боргалый?
Әллә безнең уйнаганга
Кызыгып карап торамы?!

## *Унбиш чыпчык, бер туңдырма*

Кышкы суык. Ап-ак кар.
Кар өстендә чыпчыклар —
Нәни тере йомгаклар.
Чык-чырык!
Чык-чырык!

Әйдә, сикереп җылыныйк,
Диешәләрдер инде,
Шуңа сикерешәләр,
Биешәләрдер инде...

Мин дә менә курыкмыйм
Суыктан.
Чыкмыйсың аны урамга,
Курыксаң...

Әй, син, чыпчык малае,
Ашыйсыңмы туңдырма?



Тик карап аша, яме,
Томшыгыңны туңдырма!

Унбиш чыпчык, сөенешеп,
Туңдырмага ябырылды.
Әй чукыйлар төрле яклап —
Ис китеп карап тордым:
Томшыклары ап-ак сөт.
Әй, Чык-чырык,
Борыныңны сөрт!
Ярты сәгать чукыгач,
Әллә инде ардылар,
Әллә туеп калдылар,
Очтылар да киттеләр.

Туңдырманың яртысы
Ятып калды ак карда...
Карыннары бик ачса,
Тагын килерләр әле.
Чык-чырыклар ач булмас
Айнур дуслары барда!



## *Кар ява да кар ява...*

Кар ява да кар ява,
Рәхмәт инде карларга:
Юлларымны ак иткән,
Бөтен дөнья ялт иткән!

Рәхмәт инде карларга:
Безне көткән тауларга
Чыгарбыз менә тиздән
Чана шуып уйнарга.
Чаналарда «выжт» кына,
Чаңгыларда «выжт» кына —
Рәхәтләнеп шуарбыз,
Көрткә кереп чумарбыз!
Эзләсеннәр аннары...
Рәхмәт сезгә, карларым!

## *Буран*

Җил сызгыра,
Үрсәләнә,
Дулый буран.
Бөтен җир-күк,
Бөтен урам
Ап-ак буран
Белән тулган.
Үрсәләнә,
Дулый буран...

## *Язгы әкият*

Көмеш тамчы
Нишлим икән, диеп,
Кояшта елмаеп торды да
Тып итеп җиргә тамды.
Ә ул тамган җирдә
Җем-җем итеп ята иде
Бер күлдәвек.
Тамчы тамгач,
Кояшта көлә-көлә,
Тирә-юньгә
Әллә ничә тамчы чәчрәде.
Ә бит җиргә
Тамган иде
Нибары бер тамчы!..

## *Яз килә, яз көлә...*

Яз килә, яз көлә —
Йөзләрдә елмаю.
Кояшым, алтыным,
Сип әле нурларың!

Сип әле нурларың —
Тамчылар биесен.
Яз биргән җиркәем
Чәчкәгә күмелсен.

Кыш буе йоклаган
Гөлкәем терелгән.
Күр, ничек елмаеп
Яктыңа үрелә!
Үп әле, үп әле
Шул гөлнең битеннән.
Әллә җыр түгелә
Зәңгәр күк читеннән?

Карачы бер генә:
Бар дөнья көлә ич.
Көлмәскә, гөр килеп,
Яшел яз килә ич!



## *Яратам!*

Көмеш төсле тамчылар,
Бәллүр төсле тамчылар
Сикерешә түбәдән,
Сикерешә түбәнгә
Тып-тып итеп,
Тып итеп,
Бар дөньяны бер итеп.

Күп тамчыдан күл булыр,
Күлле җир гөлле булыр.
Йөз меңләгән тамчылар
Әнә биергә чыга
Тып-тып итеп,
Тып итеп!
Бар дөньяны бер итеп.

Язның ямьле көнендә,
Бәхет теләп җиремә,
Әллә күңелем җырлый,
Әллә тамчылар җырлый
Чың-чың итеп,
Чың итеп,
Бар дөньяны бер итеп!

Тамчы җырын яратам!
Тамчы җырын яратам!
Яратам!
Яратам!
Яратам!

## *Күке*

Санийсың да санийсың —
Күке, ничек армыйсың?
— Күк-күк,— дисең,—
күк,— дисең, —
Алда гомерең күп,— дисең.
Җирдә барлык кешеләргә
Озын гомер телисең,
Имин гомер телисең,
Матур гомер телисең.
Шулай булгач, күке дустым,
Син шундый да әйбәттер,
Синең хакта, оясы юк,
Нәселсез ул, беләмче, дип,
Сөйләүләре гайбәттер.
Әлбәттә, бу гайбәттер!



## *Язгы яңгыр*

Җирне дер селкетеп,
Күк бабай күкрәде.
Яшеннән коелган
Кылычын селтәде.

Күк бабай бик юмарт:
Җир дымга тиенсен,
Дип сипте иң эре
Бөртекле энҗесен.

## *Күке рөхсәт итте*

Мин бу көнне җәй башыннан
Түземсезлек белән көттем.
Суга чумсаң да ярый, дип,
Күке үзе рөхсәт итте.

Әй йөздем соң рәхәтләнеп:
Сагындырган Идел суы!
Күке үзе рөхсәт итте,
Курыкмыйм мин — тими суык.

Мин яратам сине, Күке,
Җирдә, ярый, син дә барсың.
Суда күпме тамчы булса,
Шуның кадәр рәхмәт яусын!

Ялварамын Табигатькә,
Сиңа озын гомер теләп.
Җирдә кеше яшәгәндә,
Син бит аңа шундый кирәк!

## *Кам-Кам*

*(Бик кыска, әллә моңсу,*
*әллә күңелле әкият)*

Шулай берзаман, туган,
Кам-Кам дигән Боз булган.
Әллә малай, ди, шунда,
Әллә инде кыз булган...
«Кам-Кам түгел,
          Там-Там син!» — дип,
Моннан һаман көлгәннәр,
Теңкәсенә тигәннәр.
Әллә болай үртәгәннәр,
Әллә серен белгәннәр...
Кам-Кам күңелсезләнгән,
Нишләргә дә белмәгән.
Аннан көлә башлаган —
Үпкәләвен ташлаган.
Көлә торгач, эрегән,
Эри торгач, кимегән.

Боз камчысы Кам-Камнан
Бер су тамчысы калган.
Ул да озак тормаган —
Тып итеп җиргә тамган.
Шулай эргән дә беткән,
Гөрләвеккә кушылып,
Елгага агып киткән...
Шулай итеп шул, туган:
Кам-Кам дигән Боз булган.
Әллә малай, ди, шунда,
Әллә инде кыз булган...
Кыз булгандыр ул, туган, —
Шулкадәр көлмәс иде,
Бик тиз эремәс иде...

## *Яңгыр*

Күренеп тора: интеккән —
Җирнең ирене кипкән...
Су эчәсе бик килгән,
Яңгыр кирәк бүгеннән...
Шулай уйлавым булды,
Күкнең теге-е-е читеннән
Килде чыкты бер болыт,
Ап-ак кар тавы булып.
Аннан каралды, тулды,
Кап-кара болыт булды.
Аннан соң ул «ишелде»,
Гүя күкләр тишелде:
Коеп та куйды инде!
Явып та куйды инде!..
Булды инде, булды ич,
Җир су эчеп туйды ич.
Шулай уйлавым булды,
Яңгыр да кинәт тынды.
Ялт итеп кояш чыкты,
Гөл керфекләрен үпте.

Күкнең бер як читеннән
Икенче як читенә
Бизәкле күпер элде,
Җиргә карады, көлде.
Җир юынды, коенды,
Яңа туган күк булды.
Рәхмәт сиңа, яңгыр дус,
Бик тә сизгер икәнсең.
Бүтән җирләрне әйләнгәч,
Тагын килеп китәрсең.



## Болыт миңа булышты

Кояш шундый кыздыра —
Кызган мичтән уздыра!
Ә бакчада җир җиләк —
Кызарып пешкән бигрәк.
Шундый да пешкән инде,
Изелеп төшкән инде.

Җиләкләрне кызганам —
Җыеп, тырыска салам.
Ә күктә кояш кызган,
Нурларын миңа сузган.
Кара инде син, кара,
Бигрәк юмарт кылана!..
Җыя торгач, арыдым,
Манма су булдым, пештем.
Шул җир җиләкләре кебек,
Үзем дә изелеп төштем.
Арыдым ла, арыдым,
Тәмле җиләкләре өчен
Рәхмәт әйтеп кояшка,
Мин болытка ялындым:
— Инде күп тә калмады,
Ярдәм итә күр, дустым:
Каплап торчы кояшны,
Тутырганчы тырысны!
Болыт мине аңлады,
Якын итте, булышты:
Каплап торып кояшны,
Җиләгемне «җыешты»!

## *Кояшка үреләм*

Гөлкәем, тибрисең,
Тибрисең җилләрдә.
Син нәрсә сөйлисең
Ул назлы җилләргә?
Үлмәдең, сулмадың,
Суздың да кулларың,
Кояшка үрелдең.
Ул сипте нурларын,
Син ямьгә күмелдең.
Сокланып туймадым,
Шул вакыт уйладым:
Мин дә бит синең күк
Яшәргә туганмын.
Яктыга үреләм,
Сузам да кулларым,
Чөнки мин синең күк
Яшәргә туганмын!





## Таң алдыннан

Җем-җем килә күлнең өсте —
Кояш алтын нурга манган.
Таңда йокы тәмле була —
Урман да йокыга талган.

Тәмле төшләр күреп йоклый
Күл буеның камышлары.

Тып-тын әле — ишетелми
Кошларның да тавышлары.

Кичен концерт биреп арган —
Бакалар да тынып калган.
Нәрсә көтә икән бар да
Тып-тын калып туар таңнан?!

## *Яме артты күңелемнең*

Алтын кояш әйтерсең лә
Назлы, йомшак әни кулы.
Башларыннан сыйпау белән
Мамык төсле җылы нуры.
Үсте гөлләрем, яшәрде,
Аннан гөрләп чәчәк атты.
Яме артты күңелемнең,
Бар дөньяның яме артты.
Кояш нуры — әни кулы,
Кагылды да күңелемә,
Чәчкә булып кереп калды
Йөрәгемнең иң түренә.

## *Урманда*

Көрән эшләпә кигән,
Әллә күрмәс дип белгән?! —
Яфрак астына кергән.

Ах, хәйләкәр, ах, наян,
Уемны белгән каян?!

Тик барыбер күрдем бит,
Кемлегеңне белдем бит!

Менә кисеп алыйм да,
Кәрзинемә салыйм да,
Кайтарыйм әле өйгә,
Бирим әле әбигә!..



## Юкә белән каен

Юл читендә юкә белән
Каен тора басып.
Тын калганнар, әйтерсең лә
Бер-берсенә гашыйк...

Икесе дә яшьләр әле,
Икесе дә яшел...
Каен-кызның зифа буен
Күмер итте яшен.

Юкә-егет түзә алмады,
Җиргә иде башын.
Йомшак җилләр генә исте,
Сөртеп энҗе яшен...

## *Күк йөзе — зәңгәр күл...*

Күк йөзе — зәңгәр күл,
Ак болыт — төнбоек.
Их, берсен, тик берсен
Алырга сузылып!

Әй кызык, шул күлдә
Елмаеп Ай йөзә.
Охшаган ул көләч
Сыңар бер зур күзгә.

Ә күлнең өстенә
Энҗеләр сипкәннәр.
Нурлары шул күлне
Яп-якты иткәннәр.

Их, шунда менеп бер,
Күлендә йөзәргә!..
Җыеп бар энҗесен,
Муенса тезәргә...
Төнбоек өзәргә...

## *Киң Идел өсләре караңгы...*

Киң Идел өсләре караңгы,
Дулкыннар өстенә кар ява.
Шул ап-ак бөртекләр, җыелып,
Ак юрган ябалар тауларга.

Киң Идел өсләре караңгы,
Ярда тик маяклар күз кыса.
Җилләрдә, тирбәлә-тирбәлә,
Мамыктай ак карлар кочыша.

## *Чәчәкләр*

Көн буе бакчадан кермимен,
Әйтерсең хәзинә эзлим мин.
Мең төрле чәчәкләр күзлимен,
Юк, гөлләр, мин сезне өзмимен.

Сез, гөлләр, шундый да сөйкемле,
Нәфисләр, хуш исле, горурлар.
Кайчан соң мин чәчкән орлыклар
Бакчага ямь биреп торырлар?!

## *Күңелле!*

Җир кызына туры карап
Кояш-егет көлгәнгәме,
Яңа ачылган чәчәк кебек
Ал таң туып килгәнгәме,
Белмим,
    никтер бик күңелле миңа.

Әллә инде көмеш чыклар
Җем-җем итеп күз кысканга,
Әллә инде Җиркәемне
Охшатканга Гөлстанга,
Белмим,
    никтер бик күңелле миңа.

Зәңгәр күктә ап-ак
Бөдрә болыт йөзгәнгәме,
Игенкәйләр таң җиленең
Иркәләвен сизгәнгәме,
Белмим,
    никтер бик күңелле миңа!

## *Эшкә оста, сүзгә кыска*

Әнә ята бүрәнә —
Әйдә, көчең җәлләмә —
Күтәр әле нығытып.
Күтәр дә шунда ыргыт.
Хәзер инде карагыз:
Кулга ышкы алабыз,
Бер, ике, өч!
Бездә — көч.
Ялт итте бит бүрәнә,
Елмаеп ята әнә!
Кабык киемен салгач,
Сап-сары булып калгач,
Нәкъ сабый бала кебек,
Тик карап ята көлеп.
Нигә көлә икән ул?
Шуны белә икән ул:
Ул кешеләргә кирәк,
Әйдә, өй салыйк тизрәк!
Бабайлар һәм әбиләр,
Апалар һәм абыйлар,

Әниләр һәм бәбиләр
Яңа өйгә керсеннәр,
Алар да бер көлсеннәр,
Рәхәтләнеп йөрсеннәр,
Тик шунысын белсеннәр:
Бу булыр оста эше —
Рәхмәт укысын кеше!
Бүрәнә бит үзе генә
Берни эшли алмас иде,
Кабыгын да салмас иде,
Үзе өй салмас иде,
Урыныннан да кузгалмас иде.
Тагын монда килегез,
Ни эшләнә — күрегез:
Алъяпкыч япкан оста,
Тирә-юньдә йомычка
Тегендә оча,
Монда оча.
Пычкы әйтә: чыж-чыж,
Ышкы йөри выж-выж,
Балта тукый: тук-тук,
Йөрмәгез монда эшсез,
Ялкауларга урын юк...

Юан-юан бүрәнәләр
Такталарга әйләнгәннәр.
Бар да эшчән,
Бар да җитез,
Ә останы күрегез сез:
Йөзләр-күзләр көлеп тора,
Куллар җилдәй йөреп тора:
«Без ясаган шкафларда
Савыт-саба чылтыр-чылтыр.
Без ясаган урындыклар
Ныктыр, ныктыр.
Безнең кулдан үткән рамнар
Җанлы сыман — җырлап тора,
Урамнарны ямьләндереп,
Тирә-юньне нурлап тора».
Кешеләрне сөендереп,
Менә шулай эшли оста.
Бигрәк җитез — коеп куя,
Эшкә оста, сүзгә кыска.

## *Өебезнең кояшы*

Бәлки, минем әбине
Сез дә белә торгансыз?
Әбиемне әби диеп
Әйтүе дә уңайсыз.
    Минем әби япь-яшь әле,
    Минем әби чип-чибәр.
    Әбине күргән кешеләр,
    Кызлар кебек син, диләр.
Әбием гел көлеп тора,
Йөзе нур сибеп тора.
Көне буе ничек армый —
Куллары биеп тора.
    Минем әби
            шундый җылы, —
    Иркәләнәсе килә,
    Яннарында песи кебек
    Сырпаланасы килә.
Түребездә балкып тора
Өебезнең кояшы.
Ничек менә әбием күк
Җылы, якты буласы?!

## *Юлга чыктым...*

Юлга чыктым. Алларымда
Әллә ничә такыр сукмак.
Кайсысыннан китәргә соң? —
Юл чатында калдым туктап.

Бер өн килде: «Вакытыңның
Кадерен бел — торма туктап.
Олы юлга алып чыксын
Үзең салган яңа сукмак!»

## *Әбием килгән!*

Өйгә кайтсам, өй балкыган —
Йортка нур иңгән.
Ерак җирне якын итеп,
Әбием килгән!

Үзен ничек сагынганны
Белгән ул, белгән.
«Күрим әле бәбкәмне!» — дип,
Әбием килгән!

## *Дәү әни*

Песи булып мияуладым,
Сыер булып мөгрәдем.
Әтәч булып та кычкырдым,
Күгәрчендәй гөрләдем.

Тавык булып кыткылдадым,
Күкәй генә салмадым.
Эт булып та өрдем инде,
Үзем бер дә армадым...

«Һау-һау!» — дигәч, Гүзәлиям
Елавын да онытты.
Кая китте күз яшьләре —
Танып булмый оныкны...

Бишектә бәби еласа,
Ни кирәген беләбез:
Елау да юк, ару да юк, —
Икәүләшеп көләбез.

## Тапкыр кыз

Татарча белмәүче кәҗәләр . . . . . . . . . . 3
Кызып китте Алия . . . . . . . . . . . . . 5
Юату . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Бака туе . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Кемгә кызым диярсең? . . . . . . . . . . .11
Әзер җавап . . . . . . . . . . . . . . . .12
Алия «кәҗәләнә» . . . . . . . . . . . . . .13
Бакчага барасы бар . . . . . . . . . . . .13
Тапкыр кыз . . . . . . . . . . . . . . . .14
Телефон . . . . . . . . . . . . . . . . . .15

## Мин андый малай түгел!

Дөрес аңлаган... . . . . . . . . . . . . .17
Ботка түгел... . . . . . . . . . . . . . .17
Карадым да карадым... . . . . . . . . . . .18
Үсәсем бар... . . . . . . . . . . . . . . .18
Алтын сукмак . . . . . . . . . . . . . . .19
Бик ярата мине эш... . . . . . . . . . . .20
Җиңелмени?.. . . . . . . . . . . . . . . .21
Кошлар туе . . . . . . . . . . . . . . . .22
Айнур үпкәләде . . . . . . . . . . . . . .24
Кызык икән... . . . . . . . . . . . . . . .27
Уйный-уйный үсәм мин . . . . . . . . . . .28

Мин андый малай түгел! . . . . . . . . . . . . 30
Дәүдер җилнең авызы . . . . . . . . . . . . . 31
Акланды... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Килми калмас әле ул... . . . . . . . . . . . . 33

## Яратам!

Кайт, песием! . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Куян . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Тавык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Бал корты . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Чебен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Куян гозере . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Кызылтүш . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Унбиш чыпчык, бер туңдырма . . . . . . . . . 44
Кар ява да кар ява... . . . . . . . . . . . . 47
Буран . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Язгы әкият . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Яз килә, яз көлә... . . . . . . . . . . . . . 50
Яратам! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Күке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Язгы яңгыр . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Күке рөхсәт итте . . . . . . . . . . . . . . 55
Кам-Кам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Яңгыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Болыт миңа булышты . . . . . . . . . . . . . 60
Кояшка үреләм . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Таң алдыннан . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Яме артты күңелемнең . . . . . . . . . . . . 65

Урманда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .66
Юкә белән каен . . . . . . . . . . . . . . . . .68
Күк йөзе — зәңгәр күл... . . . . . . . . . . .69
Киң Идел өсләре караңгы... . . . . . . . . .70
Чәчәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .70
Күңелле! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .71
Эшкә оста, сүзгә кыска . . . . . . . . . . . .72
Өебезнең кояшы . . . . . . . . . . . . . . . .75
Юлга чыктым... . . . . . . . . . . . . . . . .76
Әбием килгән! . . . . . . . . . . . . . . . . . .76
Дәү әни . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .77

Литературно-художественное издание для детей

*Зиятдинова Фирая Галиевна*

**ЛЯГУШАЧИЙ ОРКЕСТР**

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Ф.М.Нәгыймова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 25.07.2003.
Форматы $70\times100^1/_{16}$. Офсет кәгазе №1. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 6,5. Шартлы буяу-оттиск 27,30.
Нәшер-хисап табагы 2,99. Тираж 3000 экз. Заказ Я-501.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.